**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О промышленной политике в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
24 сентября 2018 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 21 апреля 2016 года № 24-ЗРТ «О промышленной политике в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I) следующие изменения:

1) часть 1 статьи 3 дополнить пунктом 7 следующего содержания:

«7) промышленный технопарк – объекты промышленной инфраструктуры и технологической инфраструктуры, предназначенные для осуществления субъектами деятельности в сфере промышленности промышленного производства, и (или) научно-технической деятельности, и (или) инновационной деятельности в целях освоения производства промышленной продукции и коммерциализации полученных научно-технических результатов и управляемые управляющей компанией – коммерческой или некоммерческой организацией, созданной в соответствии с законодательством Российской Федерации.»;

2) в статье 6:

а) в части 1:

пункт 6 после слов «управляющим компаниям индустриальных (промышленных) парков,» дополнить словами «промышленным технопаркам, управляющим компаниям промышленных технопарков,»;

пункт 7 после слов «индустриальных (промышленных) парков» дополнить словами «, промышленных технопарков»;

б) в части 2:

пункт 7 после слов «индустриальных (промышленных) парков» дополнить словами «, промышленных технопарков»;

пункт 9 после слов «управляющих компаний индустриальных (промышленных) парков,» дополнить словами «промышленных технопарков, управляющих компаний промышленных технопарков,»;

3) дополнить статьей $12^1$ следующего содержания:

«Статья $12^1$. **Промышленные технопарки**

1. Применение мер стимулирования деятельности в сфере промышленности, установленных настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, к управляющей компании промышленного технопарка и субъектам деятельности в сфере промышленности, использующим объекты технологической инфраструктуры и промышленной инфраструктуры, находящиеся в составе промышленного технопарка, осуществляется в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан, в случае соответствия промышленного технопарка и управляющей компании промышленного технопарка требованиям, установленным Правительством Российской Федерации, и дополнительным требованиям в случае их установления Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Подтверждение соответствия промышленного технопарка и управляющей компании промышленного технопарка дополнительным требованиям в случае их установления Кабинетом Министров Республики Татарстан к промышленному технопарку и управляющей компании промышленного технопарка осуществляется уполномоченным органом в сфере промышленности в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Уполномоченный орган в сфере промышленности осуществляет ведение реестра промышленных технопарков, управляющих компаний промышленных технопарков, подтвердивших соответствие требованиям, установленным в соответствии с частью 1 настоящей статьи. Порядок ведения указанного реестра определяется указанным уполномоченным органом.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
13 октября 2018 года
№ 69-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:
“7) сәнәгать технопаркы – сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары тарафыннан сәнәгать продукциясен җитештерүне үзләштерү һәм ирешелгән фәнни-техник нәтиҗәләрне коммерцияләштерү максатларында сәнәгать җитештерүен һәм (яисә) фәнни-техник эшчәнлекне, һәм (яисә) инновацион эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән идарәче компания – коммерциячел яисә коммерциягә карамаган оешма тарафыннан идарә ителә торган сәнәгать инфраструктурасы һәм технологик инфраструктура объектлары.”;

2) 6 статьяда:
а) 1 өлештә:
6 пунктта “индустриаль (сәнәгать) паркларның идарә итүче компанияләренә,” сүзләреннән соң “сәнәгать технопаркларына, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренә,” сүзләрен өстәргә;
7 пунктта “индустриаль (сәнәгать) паркларга” сүзләреннән соң “, сәнәгать технопаркларына” сүзләрен өстәргә;
б) 2 өлештә:
7 пунктта “индустриаль (сәнәгать) паркларны” сүзләреннән соң “, сәнәгать технопаркларын” сүзләрен өстәргә;

9 пунктта “индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренә,” сүзләреннән соң “сәнәгать технопаркларына, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренә,” сүзләрен, “индустриаль (сәнәгать) парклары идарәче компанияләренең,” сүзләреннән соң “сәнәгать технопаркларының, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренең,” сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ статья өстәргә:

“$12^1$ статья. **Сәнәгать технопарклары**

1. Сәнәгать технопаркының идарәче компаниясенә һәм сәнәгать технопаркы составында булган технологик инфраструктура һәм сәнәгать инфраструктурасы объектларыннан файдалана торган сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына карата әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне кызыксындыру чараларын куллану, сәнәгать технопаркы һәм сәнәгать технопаркының идарәче компаниясе Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән таләпләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты өстәмә таләпләр билгеләгән очракта шушы таләпләргә туры килсә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан сәнәгать технопаркына һәм сәнәгать технопаркының идарәче компаниясенә карата өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, сәнәгать технопаркының һәм сәнәгать технопаркының идарәче компаниясенең аларга туры килүе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

3. Сәнәгать өлкәсендәге вәкаләтле орган әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган сәнәгать технопаркларының, сәнәгать технопаркларының идарәче компанияләренең реестрын алып бара. Күрсәтелгән реестрны алып бару тәртибен әлеге вәкаләтле орган билгели.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 69-ТРЗ